| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.06.2020 с. Верхний Услон 449

2020 елга гомуми торак мәйданының
бер квадрат метрының уртача бәясен
раслау турында

«Россия Федерациясе субъектлары буенча 2020 елның I кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» Россия Федерациясе төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 18 сентябрендәге 553/пр номерлы боерыгы нигезендә Югары Ослан муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2014-2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 2020 елга Югары Ослан муниципаль районы территориясендә авыл җирендә яшәүче гражданнарның, яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен исәпләп чыгарганда торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясен 53 024 сум күләмендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, элемтә һәм энергетика буенча беренче урынбасары Р.Г. Мунасиповка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе В.С. Тимиряев

Бурдина Т.Н.
3 нөсхә әзерләде һәм
бастырып чыгарды.